# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2020елның 3 февраленнән № 3

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
бюджетыннан алына торган
башка бюджетара трансфертлар акчалары
исәбеннән башкарыла торган
чыгымнар юнәлеше турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оешмаларының гомуми принциплары турында», 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында», Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 28 мартындагы № 233 карары белән «Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында», Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 18 апрелендәге 224 номерлы карары нигезендә һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалын үстерүне стимуллаштыру максатларында «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында»

Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы бюджетыннан алына торган башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнарның авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итүгә юлламасын 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 3 өлешендә билгеләнгән мәсьәләләрне хәл итүгә расларга «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оешмаларының гомуми принциплары турында» һәм 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 3 өлеше хакында «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында».

2. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлегенең рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Норматив документлар» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Бәзәкә авыл җирлеге
Советы рәисе И.И.Кәшәфетдинов